РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 09 » 09 2024 г. №881

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында"гы 25.05.2021 елгы № 403 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында»гы 12.02.1998 елгы №28-ФЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елгы № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында»гы 20.02.2020 елгы 10-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 22.11.2008 елгы № ПУ-598 указы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында»гы 25.05.2021 елгы №403 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 5 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;».

1.2. 2 нче кушымтаның 5 пунктындагы 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина